# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ
# (IV чакырылыш)

IV чакырылыш XIV утырыш

**КАРАРы**

2023 елның 11 августы №36 Урыссу штп

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы милкендәге мөлкәтне арендага бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 18.12.2015 № 18 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 08.12.2005 ел, № 1 карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы мөлкәтендәге милекне арендага бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 18 декабрендәге 18 номерлы Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1 пунктының 11 абзацында “Әлеге дәүләт яисә муниципаль контрактның” сүзләрен “Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында” 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үткәрелгән конкурс яисә аукцион нәтиҗәләре буенча килешү төзелгән затка, әгәр күрсәтелгән хокуклар әлеге шартнамәне үтәү максатларында сатып алу турындагы документларда каралган булса, “дәүләт яисә муниципаль контракт” сүзләреннән соң “яисә шартнамә” үтәлүе” сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында “Рәсми Татарстан”

дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм җирлекләр Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин